# КАРАР

**04 октября 2022 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында «Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы Манзарас авылы гражданнар җыены карарын үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 03 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы Манзарас авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 916 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 475 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 475 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы Манзарас авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яна абзацны өстәргә:

- ТАССРның 90 еллыгы урамында Манзарас авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- ТАССРның 90 еллыгы урамы буенча янгын гидранты һәм комплектлаучылар сатып алу һәм урнаштыру, проект - смета документациясен эшләү;

- Парковка урыннарын төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

-Молодежная урамында Манзарас авылы тротуарын төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Манзарас
авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хәбибуллина